СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның " 26" февраленнән № 6-36

Гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән уртача район нормасы турында

Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җирләрдән крестьян(фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик минималь күләмен билгеләү максатларында һәм Татарстан Республикасының 1998 елның 10 июлендәге 1736 номерлы «Татарстан Республикасы Җир кодексы» Законының 34 статьясындагы 1 пунктына һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән барлыкка килә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләмен билгеләү тәртибе турында Татарстан Республикасының 1998 елның 10 июлендәге 1736 номерлы «Татарстан Республикасы Җир кодексы» Законының 40 статьясындагы 2 пункты таянып, Россия Федерациясе Президентының “Гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыру нормасын билгеләү тәртибе турында " 1992 елның 2 мартындагы 213 номерлы Указы һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм итү буенча РСФСР Дәүләт комитетының 10.01.1992 елдагы 3-185/51 номерлы хаты нигезендә Яңа Чишмә районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә гражданнар милкенә түләүсез авыл хуҗалыгы җирләрен гражданнар милкенә тапшыру нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән уртача район нормасын, өлешле милегеннән бүлеп бирү юлы белән төзелә торган җир кишәрлекләреннән тыш, 4 гектар күләмендә дип расларга.
2. Әлеге карарны «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В. М. Козлов